**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 ноября 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 2 ноября 2012 года № 73-ЗРТ «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 11 (I часть); 2013, № 11 (I часть); 2014, № 1 – 2, № 12 (II часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2018, № 1 (часть I); 2022, № 17 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 27 (часть I), № 56 (часть I) следующие изменения:

1) часть 2 статьи 9 после слова «Адвокаты» дополнить словами «и нотариусы»;

2) дополнить статьей $11^1$ следующего содержания:
«Статья $11^1$. **Оказание бесплатной юридической помощи нотариусами**

1. Нотариусы оказывают гражданам бесплатную юридическую помощь в случаях и в порядке, предусмотренных Федеральным законом и настоящим Законом.
2. Организация участия нотариусов в деятельности государственной системы бесплатной юридической помощи в Республике Татарстан осуществляется Нотариальной палатой Республики Татарстан.
3. Компенсация оплаты нотариальных действий, совершенных нотариусами бесплатно в рамках государственной системы бесплатной юридической помощи, осуществляется уполномоченным органом в порядке, установленном Федеральным законом.»;

3) пункт 2 части 3 статьи 12 дополнить подпунктом «д» следующего содержания:

«д) о защите наследственных прав детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, лиц из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей;»;

4) часть 2 статьи 18 после слов «такой помощи,» дополнить словами «с компенсацией оплаты нотариальных действий, совершенных нотариусами бесплатно в рамках государственной системы бесплатной юридической помощи,».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2024 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
04 декабря 2023 года
№ 119-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 өлешендә «Адвокатлар» сүзеннән соң «һәм нотариуслар» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ статья өстәргә:
«$11^1$ статья. **Нотариуслар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Нотариуслар Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда һәм тәртиптә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.
2. Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы эшчәнлегендә нотариусларның катнашуын оештыру Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы тарафыннан башкарыла.
3. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында нотариуслар тарафыннан түләүсез кылынган нотариаль гамәлләр өчен түләүне компенсацияләү Федераль законда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3) 12 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасы

өстәргә:

«д) ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның варислык хокукларын яклау турында;»;

4) 18 статьяның 2 өлешендә «компенсацияләүгә» сүзеннән соң «, дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында нотариуслар тарафыннан түләүсез кылынган нотариаль гамәлләр өчен түләүне компенсацияләүгә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                                                 Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 04 декабрь
№ 119-ТРЗ